**Республика Татарстан**
**Зеленодольский**
**муниципальный район**
**Глава**
**муниципального образования**
**«поселок городского**
**типа Нижние Вязовые»**

**Татарстан Республикасы**
**Зеленодол**
**муниципаль районы**
**«Карамалы тау шэһэр**
**тибындагы поселок»**
**муниципаль берэмлекнен**
**Башлыгы**

422500, Карамалы Тау штп, Беренче Май ур., 70

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**01.11.2018** **№42**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Түбән Карамалы Тау җирлегенең Рус Шырданы авылында гражданнар җыенын билгеләп кую турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 17 статьясы нигезендә

**Карар бирәм:**

1. 2018 елның 24 ноябрендә Зеленодольск муниципаль районы Түбән Карамалы Тау җирлегенең Рус Шырданы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Билгеләү:

2.1. үткәрү вакыты-8.00 сәгатьтә;

2.2. үткәрү урыны-Рус Шырданы авылы, Гагарин урамы, Өчпрестольле Петропавловск гыйбадәтханәсе бинасы.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2019 елда үзара салым кертүгә Зеленодольск муниципаль районы Түбән Карамалы Тау җирлегенең Рус Шырданы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән 500 сум күләмендә, моннан тыш: 1 һәм 2 группа инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның толларыннан, күп балалы гаиләләрдән, һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалардан гайре, сез риза буласызмы:

- Рус Шырданы авылында Гагарин урамына вак таш салу;
- Рус Шырданы авылы зиратын төзекләндерү.

« ӘЙЕ» «ЮК».

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында халыкка игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталына Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) шулай ук махсус мәгълүмат стендларында (түбәндәге адреслар буенча урнашкан: Карамалы Тау ш.т.п., Беренче Май ур., 70 йорт, ҖҮИ бинасында, Карамалы Тау ш.т.п., Беренче Май ур., 70 йорт (җирлекнең административ бинасы), Карамалы Тау ш.т.п., Беренче Май ур., 30 йорт, «Адел» кибете янында мәгълүмат щиты; Карамалы Тау ш.т.п, Беренче Май ур., 2а йорт, вокзал яны мәйданында мәгълүмат стенды, «Диана» кибете янында мәгълүмат стенды, Карамалы Тау ш.т.п, Кузнечная ур., 16а йорты, «Рубин» кибете янында мәгълүмат стенды, Карамалы Тау ш.т.п, Б. Кочемиров ур., 2а, «ЮСОН» кибете янында мәгълүмат стенды, Протопоповка авылы, Кооператив ур., 15а, ИП Яфизова кибете янында мәгълүмат щиты, Олы Ходяшево авылы, Үзәк урамы, 2а, Үзәк урамы, 42нче йорт, шәхси эшмәкәр Навасардян кибетендә 7 көн дәвамында мәгълүмат щиты.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы Ю.М. Некрасова